ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 август 2024 ел № 5134

Башкарма комитетның 2024 елның 22 гыйнварындагы 324 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пунктына туры китереп, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Күп балалы гаилә статусы билгеләү турында» 2024 елның 18 июнендәге 20-09/8480 номерлы хаты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2024 елның 22 гыйнварындагы 324 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2024 елның 11 мартындагы 1506 номерлы Карары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турында нигезләмәгә, 7 пунктның 3 пунктчасындагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«күп балалы гаиләнең таныклык күчермәсе яки балаларның туу турында таныклык күчермәләре;».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов